| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯШЕЛ ҮЗӘН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 феврале №2

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җеназа эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җеназа эшләре турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 73 номерлы карары белән, Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. 1 нче кушымтага һәм 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә, Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 6424,98 суммасында билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2020 елның 31 январындагы 1 нче номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин

Яшел Үзән муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл жирлеге башкарма
комитетының 2021 елның 1
февралендәге 2 нче карарына
1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлегендә җирләү буенча
гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3501,30 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 997,40 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Яшел Үзән муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл жирлеге башкарма
комитетының 2021 елның 1
февралендәге 2 нче карарына
2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлегендә җирләү буенча
гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне гыйбадәтләү | 618,59 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2882,71 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 997,40 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |